Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2019 нчы елның 25 нче октябре 259№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Советының 2016 нчы елның 22 нче
августындагы 46 номерлы “2016-2021 нче
елларга һәм 2030 нчы елга кадәрге план чорына
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе"
карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2014 нче елның 28 нче июнендәге 172-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында" гы Федераль законнар, Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә һәм 2019 нчы елның 5 нче апрелендәге 31-ТРЗ номерлы "2030 нчы елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында “Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 нче елның 18 нче декабрендәге 534№ боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) дәрәҗәсендә социаль-икътисадый үсешне стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнамәләр нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2016 нчы елның 22 нче августындагы 46 номерлы “2016-2021 нче елларга һәм 2030 нчы елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.5 нче бүлек өстәргә:

**“3.5. “Алтын Үзән” муниципаль сәнәгать мәйданчыгын үстерү**

Әлки муниципаль районын үстерүнең мөһим элементы булып аның инвестицион җәлеп итүчәнлеген тәэмин итү тора.

Әлки муниципаль районының инвестиция эшчәнлеге аның гомуми икътисади тормышының мөһим өлеше булып тора һәм район эшчәнлегендә мөһим роль уйный.

Инвестиция эшчәнлеген оештыру дәрәҗәсенә, аның үсешенә җәмәгать җитештерүенең күләме, икътисадның төр структурасы, потенциаль инвесторларның территориягә акча салу теләге, инженерлык инфраструктурасы һәм торак-коммуналь хуҗалыгы, халыкның мәшгульлеге, район бюджеты һәм җирлекләр бюджетларының керемнәре бәйле.

Шулай итеп, инвестицион эшчәнлек муниципаль хакимиятләр тарафыннан иң зур игътибар предметы булып тора.

Әлки муниципаль районының 2016-2021 нче елларга һәм 2030 нчы елга кадәрге план чорына социаль-икътисадый үсешенең төп максатларыннан чыгып, инвестицион

эшчәнлекнең максаты түбәндәгедән гыйбарәт: район территориясендә уңай инвестицион климат һәм икътисадый үсешне 2 тапкырдан артык тәэмин итү.

Куелган максатка ирешү өчен ирешелгән позицияләрне саклау һәм Әлки муниципаль районының инвестицион потенциалын арттыру бурычын хәл итәргә кирәк.

Инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, өстәмә эш урыннары булдыру максатларында Әлки муниципаль районы территориясендә 35,9 га мәйданда "Алтын Үзән" муниципаль сәнәгать мәйданчыгы булдырылды. Сайланган территориянең уңайлылыгы Казан – Тольятти трассасына якын булуы белән билгеләнә – 1 километрдан кимрәк. Мәйданчык территориясендә 10 резидент җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру планлаштырыла. Әлки муниципаль районы Советы карары белән “Алтын Үзән” сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчәнлек алып баручы предприятиеләрне 5 елга арендага биргән өчен түләүдән азат итү кабул ителде.

2018 нче елда мәйданчык территориясендә артезиан скважинасы бораулаган, 630 кВт егәрлекле трансформатор подстанциясе урнаштырылган.

Резидентларга җир участоклары бүлеп бирелгән, алар тарафыннан җитештерү биналары төзелеше башланган инде.

Әмма мәйданчык резидентлар өчен кызыклы булсын өчен мәйдан эчендә 1,2 км юл төзергә һәм 850 метр озынлыкта газ сузарга кирәк.

Район җитәкчелеге яңа резидентларны җәлеп итү белән актив шөгыльләнә.

Әлеге сәнәгать мәйданчыгында производстволарның үсеш мөмкинлекләре турында мәгълүмат район сайтында урнаштырылган, район газетасында даими яктыртылып тора, шәхси эшмәкәрләр белән очрашуларда әйтелә.

2. 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3. Әлеге карар Әлки муниципаль районы http://alkeevskiy.tatarstan.ru/ сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы Никошин А.Ф.